**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Илбәк авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Илбәк авылы № 70 "21" декабрь 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 гыйнварындагы 76 номерлы карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (26.09.2014 №99, от 01.12.2016 №40, 04.09.2017 №58, 03.07.2018 №95, 15.03.2019 №120, от 19.02.2020 №150, от 11.08.2021 №31, 23.06.2022 №59 карарлар редакциясендә)

Муниципаль норматив хокукый актларны Россия Федерациясенең гамәлдәге шәһәр төзелеше кодексына туры китерү һәм 2022 елның 14 июлендәге 350-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законны үтәү максатыннан

Илбәк авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 гыйнварындагы 76 номерлы карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы «Илбәк авыл җирлеге» җирдән файдалану һәм муниципаль берәмлек төзелеше кагыйдәләренә 26.09.2014 №99, от 01.12.2016 №40, 04.09.2017 №58, 03.07.2018 №95, 15.03.2019 №120, от 19.02.2020 №150, от 11.08.2021 №31, 23.06.2022 №59 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 25 статьяның 2 өлешендәге 4 пунктын «, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган критерийлар» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Л.Р.Әсәдуллина